Һәр илдәге белем бирү системасы үзенчә, ягъни иҗтимагый-сәяси вәзгыять үзенчәлекләреннән чыгып, милли-мәдәни аермаларны исәпкә алып төзелгән булуга карамастан, уку процессын оештыруда үзара охшаш билгеләр дә бар. Дәрес шулардан иң мөһиме һәм традицион форма булып санала (бөтен сыйныф белән берьюлы эшләү). Билгеле булганча, дәрестә укытучы укучыларга белем бирә: яңа материалны аңлату юлы белән аларда белем һәм күнекмәләр булдыра, балаларның уку эшчәнлеген бәяли. Димәк, укытучыларның эше барыннан да элек белемнәрне хәбәр итүгә, әзер хәлдәге чишелеш юлларын күрсәтүгә юнәлтелгән.

Соңгы унъеллыкта җәмгыятебездә барган үзгәрешләр белем бирү системасына да йогынты ясады (мәсәлән, Болония процессы). Ул дөньякүләм белем бирү киңлеге үсеше тенденцияләрен исәпкә алып үзгәрергә мәҗбүр. Димәк, педагогик тәрбия һәм практика заманча таләпләргә җавап бирергә тиеш. Моның өчен укучыга карата уңай мөнәсәбәт белән бергә укытуның эчтәлеге дә үзгәререгә бурычлы. Бу исә эксперименталь һәм хосусый мәктәпләр, лицейлар, гимназияләр ачылуга этәргеч ясады. Аларда, белем бирүнең традицион формалары белән беррәттән, укытуның сыйфатын сизелерлек күтәрердәй заманча технологияләр дә уңышлы файдаланыла. Укытуның эчтәлеге дә үзгәреп тора: мәсәлән, XX гасырның беренче яртысында алга киткән илләрдә – башлангыч белем бирү, 1950 нче елларда урта белем бирү массакүләм төс ала. Безнең чорда исә югары белемле булу җәмгыятьнең үсеш дәрәҗәсенә бәйле, шулай ук кешенең тормыш дәрәҗәсе үсү аның яшәешендә белемнең әһәмиятле фактор булуын да раслап тора.

«Инновация» (яңа, заманча) термины XIX гасырдан ук кулланылышта йөри. Аны, төрле халыкларның мәдәниятләре бер-берсенә йогынты ясый, хезмәттәшлек итә башлагач, америка галиме Джеймс У.Боткин тәкъдим итә, чөнки XX гасыр башы – җитештерү өлкәсенә яңалыклар кертү турындагы фән барлыкка килү белән мәгълүм. Педагогика өлкәсендәге яңалык проблемалары белән шөгыльләнә башлау узган гасырның 50 нче еллар ахырына туры килә.

Безнең илдә фәнни әдәбиятта бу төшенчә XX йөзнең 80 нче елларында күренә башлый. Әмма, идеологик киртәләр аркасында, әлеге яңалыкларның керүе һәм үсеше бик акрын темплар белән бара. Бары тик илдә демократик үзгәрешләр башлангач кына, киң таралыш таба.

«Инновация» терминын без педагогик тәҗрибәдәге махсус эшләнгән яисә «очраклы рәвештә генә алынган» яңалык итеп кабул итәбез. Фәнни әдәбиятта «яңалык» һәм «инновация» төшенчәләре төрлечә аңлатыла. Яңалык – ул укыту процессына караган яңа чара (яңа метод, яңа методика, яңа технология һ.б.). Әлеге чараны үзләштерү процессын инновация дип саныйлар. Хәзерге заман таләпләренә туры килә торган белем бирү шәхесне җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләргә, тормыш ситуацияләренә, фән нигезләрен ныклы итеп үзләштерүгә әзерләүне күздә тота. Соңгылары исә – яңа технологияләрне файдаланып, иҗади мөмкинлекләрне, фикерләүне, аралашу күнекмәләрен үстерү – программаларда каралган. Заманча технологияләрне кулланганда, өйрәтү процессы буларак, дәрес системасыннан укучыларның «төп яшәү формасына» күчүе күзәтелә (дәрес-иҗат, дәрес-хезмәт, дәрес-аралашу, дәрес-дуслык, дәрес-әңгәмә һ.б.).

Татар теленә өйрәткәндә, инновацион якын килү белем бирү процессын яңарту-үзгәртү күзлегеннән чыгып карарга мөмкинлек тудыра, гадәти «репродуктив» юнәлеш вакытындагы кебек уңай нәтиҗә гарантияләнә. Шул ук вакытта, белем бирүгә технологик яктан чыгып якын килү укучыларга билгеле бер белемнәрне хәбәр итүгә, эшчәнлекне укытучы тәкъдим иткән үрнәк буенча оештыруга юнәлтелә: яңарту-трансформацияләү уку-укыту процессы турындагы традицион күзаллауны үзгәртә, ул исә, үз чиратында, танып белү эшчәнлегенең тикшеренү характерында булуын, ягъни укучыларның уку-танып белү эшчәнлеген эзләнү формасында оештыруны тәэмин итә. Әлеге формада якын килү нәтиҗәле эшчәнлек аркасында традицион белем бирүне үзгәртеп кору мөмкинлегенә ия булып тора. Ул куелган максатларга ирешүне уңай хәл итә, димәк, көтелгән нәтиҗәгә китерә.

Әйтергә кирәк, теләсә кайсы чараның яңалыгы – чагыштырмача төшенчә. Бер укытучыга яңа булган күренеш башкалар өчен күптән таныш, хәтта искергән үк булырга да мөмкин, шунлыктан яңалык проблемасын конкрет-тарихи аспектта карарга кирәк. Билгеле бер вакытта барлыкка килеп һәм чагыштырмача яңа булган аерым мәсьәләләрне чишкәннән соң, вакытлар узу белән, яңалык гадәти нормага әйләнә, аннан соң искерә төшә һәм гамәлдән бөтенләй төшеп калу ихтималы да бар. Яңалыкны тормышка ашыру җиңел эш түгел, чөнки ул табигате белән чагыштырмача консервативрак була.

Традицион белем бирүне заманча белем бирүдән үзенчәлекле төшенчәләр, терминнар, укытуны нәтиҗәле итүгә төрлечә якын килүләр, лингводидактик проблемаларны тикшерү теле һ.б. аерып тора. Традицион технологияләрнең төп сүзләре дисциплина, үзконтроль, характер, акылны үстерү, заманча технологияләрнеке – эшчәнлек, ирек, бербөтен шәхес, өйрәнүченең ихтыяҗлары, кызыксыну һ.б.ш.

Татар теленә инновацион технология буенча өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыруны аңлата. Бу вакытта ул төп нәтиҗәгә – укучының актив коммуникатив эшчәнлеккә омтылуын алдан сизүгә, баланың хисси һәм интеллектуаль мөмкинлекләрен файдаланып аралашуга юнәлтелә.

Татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып, түбәндәгеләр санала:

1) укучыда өйрәнә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;

2) укучының танып белү активлыгын арттыру;

3) тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;

4) укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү һәм инициативасын тагын да үстерү.

Заманча технологияләр белән эшләгәндә, укытучы үз ролендә, режиссер, укучы, нинди дә булса эшне оештыручы (мәсәлән, уенны), консультант яки башка һөнәр ияләре сыйфатында булырга мөмкин.

Педагогик һәм методик әдәбиятта, шулай ук гамәлдә дә «технология», «педагогик технология», «белем бирү технологиясе» дигән терминнар һаман саен ешрак кулланыла. Алар нәрсәне аңлата соң? Әлеге төшенчәләрнең нигезен ачыкларга тырышып карыйк. Бу терминнарны татар телен чит тел буларак укытканда да кулланып була һәм ул мондый яссылыкта беренче тапкыр тәкъдим ителә [1: 314-317; 2: 4-7].

«Технология» терминының эчтәлеге энциклопедик сүзлектә (грек сүзе *techne* – сәнгать, осталык һәм *logos* – тәгълимат) фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланыла торган методлар, алымнар һәм ысуллар җыелмасы дип күрсәтелә [3: 689, 390].

Татар телен чит тел буларак укытуда яңа технологияләрне куллану гамәли эштә төп урынны алып торырга тиеш. «Технология» термины укытучының үз эшендә куллана торган алым һәм ысуллар җыелмасын, шулай ук татар теленә өйрәтүдә файдаланыла торган уку материалларын (укыту-методик комплект – УМК, компьютер технологиясен аудио- һәм видеоматериалларны) күздә тота. Басылып чыккан укыту-методик комплектлар, коммуникатив юнәлешле булып, укытучы тарафыннан укучының белемен тикшерүне һәм укучыларның үз-үзләрен тикшерүен оештыра алырдай биремнәрне дә үз эченә ала. Проблемага болай якын килү чит телдә аралашуны табигый, гадәти шартларга якынайтырга мөмкинлек тудыра. УМК тел өйрәнүчеләрдә кызыксыну уятуга, танып белү һәм тикшеренү сәләтен үстерүгә булышлык итә. Татар теленә өйрәтүнең ни дәрәҗәдә уңышлы булуы инновацион технологияләрне

оста файдалануга, укучылар белән дустанә мөнәсәбәт булдыруга да бәйле.

«Педагогик технология» төшенчәсенә галимнәр тарафыннан төрле мәгънә салынган. Мәсәлән, танылган педагог Б.Т.Лихачев аны барлык педагогик процессның оештыру-методик инструментлар җыелмасы, тәэсир итү объектына психологик-педагогик юнәлешләрнең бердәмлеге дип саный. М.А.Чошанов әлеге терминга дидактик система составына кергән процессуаль өлеш буларак карый. И.П.Волков фикеренчә, педагогик технология – барлык процессны тасвирлау аша куелган нәтиҗәләргә ирешү. Г.К.Селевко педагогик технология төшенчәсен өч аспектта тикшерә: беренчесе – фәнни, ягъни педагогика фәненең «белем бирүнең максатын, эчтәлеген һәм методларын өйрәнә, педагогик процессларны проектлый торган» өлеше; икенчесе – процессуаль-тасвирлаулы, ягъни күз алдында тотылган нәтиҗәләргә ирешү өчен кирәк булган максат, эчтәлек, метод, ысул һәм алымнардан торган процессны тасвирлау; өченчесе – процессуаль-тәэсирле, ягъни педагогик процессны гамәлгә ашыру, «барлык шәхси, инструменталь һәм методологик педагогик чараларны хәрәкәтләндерү» [4: 189]. Димәк, педагогик технология – ул заманча белем бирү процессының шәхесне активлаштыруга һәм укучының мөмкинлекләре ачылуны тәэмин итүгә юнәлтелгән хәрәкәтчән төп көче.

Белем бирү технологиясе үзенең табигате буенча укытучы һәм укучының эшчәнлеген бердәм иҗади процесска кушу өчен төзелгән, тиешле алымнар, методлар һәм чаралар нигезендә аларның уртак эшчәнлегенә юнәлтелгән. Димәк, педагогик технология – алга куелган бурычны үтәү өчен кирәкле мөмкинлекләр белән тәэмин ителгән өйрәнүче һәм өйрәтүченең программалаштырылган эшчәнлеге; уку-укыту процессының барлык компонентлары да үзара бәйләнештә булган система моделе.

«Белем бирү технологиясе» төшенчәсенең эчтәлегенә килгәндә исә, ул – укыту техникасын, ягъни татар телен укыту техникасын һәм алымнарын күз уңында тота. Татар теле укытучысы уку процессын нәтиҗәле оештыру өчен, укучының да куйган хезмәтен исәпкә алып, лингводидактика, педагогика, психология, методика һ.б. фәннәрнең соңгы казанышларына таянып эш итәргә тиеш. Шуннан чыгып, белем бирү технологиясе аның эчтәлегенә лингвистика (фонетик, лексик, грамматик материал сөйләм үрнәкләрендә, структураларында, диалогик модельләрдә, үрнәк җөмләләрдә, җайлаштырылган һәм аутентик текстларда тәкъдим ителә) һәм психология (сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәнү вакытында формалашкан әйтелеш, лексик, грамматик күнекмәләр һ.б.) күзлегеннән карауны таләп итә.

Белем бирү технологиясе түбәндәге сорауларга җавап бирә: балаларны ничек укытырга, ягъни белем бирү югары нәтиҗәгә китерсен өчен, уку-укыту процессын ничек оештырырга, ниндирәк принциплар, методлар, алымнар һәм чаралар сайлап алырга була һ.б.

«Белем бирү технологиясе» төшенчәсен фәнни әйләнешкә кертүебезнең максаты – татар телен чит тел буларак укыту методикасын яңа баскычка күтәрү, укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру, укучыларның әлеге предметка карата кызыксынуларын көчәйтү. Укыту технологиясе лингвистика, психология, педагогика фәненә нигезләнсә, нәрсәне өйрәтергә һәм ничек өйрәтергә дигән мәгълүм сорауларга тулысынча җавап бирә ала. Бары тик яхшы әзерлекле укытучы гына белем бирүне югары дәрәҗәдә алып барырга, укучыларда тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу өлкәсендә ныклы белем һәм күнекмәләр булдырырга сәләтле. Моның өчен ул дәресләрдә укытуның заманча технологияләрен куллануның мөһимлегенә һәм нәтиҗәлелегенә төшенергә тиеш. Әмма, практика күрсәткәнчә, күп кенә укытучылар татар теленә нәтиҗәле өйрәтә торган әлеге мөмкинлектән файдаланырга ашыкмыйлар. Консерватив фикерләү көчлерәк булганлыктан, нигездә, традицион методикага өстенлек бирәләр.

Яңа мәгълүмати технологияләрне укыту процессына кертү – заман таләбе. Хәзер компьютер сыйныфы булмаган мәктәпне күз алдына китерүе дә авыр. Шуңа күрә дә соңгы елларда яңа информацион технологияләрне укыту процессында куллану актуаль мәсьәләләрдән санала. Бу, үз чиратында, яңа техник чараларны гына түгел, бәлки укытуның яңа метод һәм формаларын, гомумән, укытуга яңача якын килүне аңлата. Рус мәктәбендә татар телен укытуның төп максаты – укучыларны аралашырга өйрәтү, аларның аралашу культурасын формалаштыру һәм үстерү. Бу уңайдан, төп бурычларны түбәндәгечә күрсәтергә була:

1) татар теле дәресләрендә компьютер технологияләрен куллану мөмкинлекләрен ачыклау;

2) махсус программалар нигезендә, татар теленә өйрәтү юлларына һәм аларны гамәлдә куллану мөмкинлекләренә төшендерү;

3) телгә өйрәткәндә, компьютер технологиясенең нәтиҗәле чара икәнлеген аңлату.

Белем бирү процессында еш кулланыла торган информацион һәм коммуникацион технология (ИКТ) чаралары: УМК, компьютер, мультимедиа проекторы, интерактив такта, электрон сүзлекләр һәм энциклопедияләр, Интернет-ресурслар, аудио- һәм видеотехника, DVD һәм CD дисклар һ.б. Шуларның кайберләренә методик яссылыктан чыгып, аңлатма биреп китик.

Интернет-ресурс – глобаль Интернет челтәре укытучыга һәм укучыга үзе теләгән кирәкле информацияне тиз арада эзләп табарга ярдәм итә. Интернет түбәндәге дидактик бурычларны хәл итә:

1) укучыларның сүзлек байлыгын үстерә;

2) укуга һәм язуга караган белем һәм осталыкларын формалаштыра;

3) Интернеттагы материалларны файдалану, дәрестә аларны киң куллану татар телен өйрәнүгә карата кызыксынуны көчәйтә, чөнки хәзер Интернет челтәрендә татар телендә дә мәгълүмат бик күп. Өстәвенә ул укучыларга иптәшләре белән онлайн формада аралашу мөмкинлеге тудыра.

Проектор статик сурәтне зур экранга чыгара. Уңай ягы: укытучы аны кирәк вакытта җибәрә, туктатып тора ала; укучыларда эстетик зәвык уята; күрсәтеп бетермәгән өлешләрне балалар үзләре уйлап әйтергә яки язарга тиеш булалар һ.б.

Электрон сүзлек кирәкле мәгълүматны эзләп табарга һәм аның белән тиешле биремне үтәргә ярдәм итә. Дәресләрдә Интернет-ресурслардан файдалану сөйләм эшчәнлегенә караган бик күп дидактик бурычларны хәл итә:

1. Интернеттан алынган тавышлы текстлар нигезендә тыңлап аңлау күнекмәләрен камилләштерә;

2. Интернет челтәре материалларын файдаланып укуга караган белем һәм осталыклар формалаштыра;

3. Интернет челтәре материалларын файдаланып язган сочинение, изложение, рефератны иптәшеңә җибәреп, аның белән язма рәвештә хәбәрләшү мөмкинлеге туа, яки язма сөйләмне камилләштерә.

Шулай итеп, яңа мәгълүмати чаралардан, компьютер программаларыннан, татарча Интернет-ресурслардан (http://www.tatknigafund.ru; www.tatar.ksu.ru; http://belem.ru/; http://www.tatar-inform.ru/; tazbash.ru; kitap.net.ru; anatele.ef.com) урынлы һәм даими файдалану татар теленә карата кызыксынуны көчәйтә һәм белем сыйфатын да сизелерлек арттыра.

Татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне куллану мөмкинлекләре түбәндәгечә классификацияләнә:

1. Укыту-тәрбия процессында нинди урын бирелүе буенча: төп һәм ярдәмче чаралар.

2. Адресат буенча (укытучы һәм укучы). Ләкин чараларны адресат буенча бүлгәндә, төгәл генә укытучы яки укучыга аерып булмый. Гадәттә, укытучыга стандарт, программа, дәреслекнең методик кулланмасы, УМК, башка төрле әдәбият; укучыга дәреслек, эш дәфтәре, дәреслекнең электрон кушымталары, аудио- һәм видеоязмалар, сүзлекләр һ.б. тәкъдим ителә. Әмма бер үк вакытта бу чаралардан укытучылар һәм укучылар да файдалана ала. Димәк, әлеге бүленеш шартлы рәвештә генә булырга мөмкин.

3. Ишетү, күрү һәм күрү-ишетү чаралары.

4. Техник һәм традицион чаралар.

Укыту-методик комплектка кергән чаралар төп чараларны тәшкил итә.

Программа – укытучыга укыту-тәрбия процессын оештыруга ярдәм итә торган төп документ. Программада татар теленә өйрәтүнең төп юнәлешләре билгеләнә, тел һәм сөйләм материалының күләме, сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәтүнең максат-бурычлары күрсәтелә, мәдәният өлкәсенә караган материалларны куллануның әһәмияте ассызыклана.

Укытучы өчен методик кулланма – укыту-тәрбия процессын оештыруда мөһим чараларның берсе. Анда дәресне оештыру буенча киңәш-тәкъдимнәр, эш алымнары, юнәлешләре күрсәтелә һәм УМКның эчтәлеге бирелә.

Дәреслек – укучының белем һәм күнекмәләр үзләштерүдә төп чарасы. Ул УМКда каралган системаны (төп теоретик күрсәтмәләрне биремнәр, башка төрле гамәлләр аркылы) тормышка ашыра. Шуңа күрә дә укучы дәреслекнең төзелешен, кайда нәрсә урнашуын (мәсәлән, шартлы билгеләр), аны ничек файдалану юлларын беренче дәрестән үк аңлап калырга тиеш була.

Аудиоязма – татар әдәби сөйләмен тыңлап аңларга, дөрес сөйләм күнекмәләре булдырырга ярдәм итә.

Таратма әсбапларга сыйныфта һәм өйдә эшләү өчен кирәк булган әйберләр, предметлы һәм сюжетлы рәсемнәр, карточкалар кирә.

Интернет челтәре дәресне һәм дәрестән тыш эшне оештыру өчен, укучыга сыйфатлы белем бирүдә, татар теленә карата кызыксыну уятуда мөһим чара булып тора.

Татар теленә өйрәтүнең өстәмә чараларын өч төркемгә аерып була: укытучы өчен генә, укучы өчен генә, укытучы һәм укучы өчен дә булган чаралар.

Өстәмә чараларга төрле методик кулланмалар, мәкаләләр, сүзлекләр, рәсемнәр, әйберләр, уенчыклар, таблицалар, таратма әсбаплар һәм, әлбәттә, компьютер, Интернет кирә.

Информацион һәм коммуникацион технологияләр (ИКТ) мәгълүматны тапшыру, тарату һәм төрле характердагы хезмәт күрсәтү өчен файдаланыла торган киң спектрлы цифрлы технологияләр (компьютер җайланмасы, мультимедиа чаралары, электрон почта, кәрәзле телефон, Интернет һ.б.).

Укыту-тәрбия процессында кулланыла торган ИКТ чаралары ике төргә бүленә: аппаратка һәм программага бәйле булган чаралар.

Аппаратка бәйле булган чаралар: компьютер – информацияне эзләп табу һәм аны эшкәртә торган универсаль җайланма; принтер – укытучы яки укучы тапкан, үзе язган мәгълүматны кәгазьгә төшерергә ярдәм итә торган җайланма; сканер – язма текстның төп нөсхәсен күчереп бирү һәм аның белән эшләү мөмкинлеге тудыра торган җайланма; ксерокс – язма мәгълүматны тиешле күләмдә чыгарып бирә торган җайланма; видеокамера, аудио- һәм видеомагнитофон, фотоаппарат тирә-юньдәге образлы мәгълүматны турыдан-туры укыту-тәрбия процессына кертеп җибәрергә ярдәм итә.

Программага бәйле булган чаралар барлык мәгълүмати чаралар белән эшләүне тәэмин итә. Информацион чыганаклар – компакт-дисклар, информацион сайтлар, Интернет һ.б.

Комплекслы өйрәтү пакетлары (электрон дәреслек, дәреслекнең электрон кушымтасы) белем бирү процессында катнашучыларны (укучылар, укытучылар, ата-аналар, мәктәп администрациясе) мәгълүмат белән тәэмин итә.

Хәзер мәгариф оешмалары тел фәннәрен өйрәтүгә, аны гамәлдә куллануга зур әһәмият бирә. Бу рус мәктәпләрендә татар теле укытуга да карый. Укыту процессында яңа информацион һәм коммуникацион технологияләрне файдалану компьютерның өйрәтү чарасы буларак кулланылу офыкларын тагын да киңәйтә. Татар телен өйрәнү өчен дә глобаль Интернет челтәренең мөмкинлекләре җитәрлек [5: 432].

Мультимедиа өйрәтү программаларыннан тыш, компьютер тестлар әзерләүдә һәм аның нигезендә укучыларның белемнәрен тикшерүдә, дидактик материаллар әзерләүдә, Интернет-ресурсларыннан файдаланганда, укыту процессына мониторинг үткәрүдә, укучыларның проект эшчәнлеген тикшерүдә алыштыргысыз ярдәмче булып тора.

Заманча технологияләр фән-техника үсеше, мәгълүмати-компьютер һәм иҗтимагый-иктисадый шартлар белән бәйле. Инновацион белем бирү укытуның теоретик нигезләрен үзгәртүне, яңа педагогик фикерләү күнекмәсен булдыруны, студентларның һөнәри компетентлыгын үстерүне дә күз уңында тота [4: 316-317].

Заманча технологияләрнең кайберләре түбәндәгеләр: компьютер технологиясе; укучыга аерым якын килеп укыту технологиясе; модуль нигезендә укыту технологиясе; мәгълүмати-коммуникатив технология; үстерелешле укыту технологиясе; телгә On-line режимында өйрәтү технологиясе; мәктәптә югары уку йорты технологияләрен файдаланып укыту: дәрес-лекция, дәрес-практикум, дәрес-семинар, дәрес-зачет һ.б.; уен технологиясе; сәламәтлек саклау технологиясе; алгоритмга нигезләнгән информацион һәм коммуникацион технологияләр; проектлар методы; проблемалы-эвристик технология; дистанцион укыту технологиясе; коммуникатив, лингвистик һәм этнокультурологик компетенцияләргә нигезләп телгә өйрәтү технологиясе; укучының «Уңышлар портфеле» технологиясе; «Тел архивы» технологиясе; Сингапур проекты; предметара бәйләнешкә нигезләнгән интерактив дәресләр; ярыш формасында уздырыла торган дәресләр; иҗтимагый-мәдәни чараларга охшатып дәрес уздыру (дәрес-сәяхәт, дәрес-концерт, дәрес-экскурсия); төрле оешмалар эшчәнлегенә охшатып дәрес уздыру (парламентта дебатлар, пресс-конференция, аукцион).

Педагогик технология принциплары: тәрбия аркылы белем бирү принцибы; баланы төрле яклап үстерү принцибы; укуда, үсүдә һәм тәрбияләүдә уңышлы булу принцибы;

материалны даими рәвештә кабатлау принцибы; уку өчен тиешле психологик халәт булдыру принцибы; укучыларның уку процессында мөмкин кадәр тулырак катнашу принцибы.

Көндәлек эшчәнлектә педагогик технологияләрдән файдалану – укыту-тәрбия процессының эчтәлеген үзгәртә, укучылар ирешәчәк осталык һәм күнекмәләр ныклы була һәм белемнең сыйфаты да арта.

Белем бирү технологиясе түбәндәге компонентлардан тора:

- уку материалын үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү һәм бер төрле белемле укучыларны аерым төркемгә җыю;
- укучыларның уку эшчәнлеген оештыру һәм аларда кызыксыну уяту;
- уку чараларының йогынтысы. Бу этап, икенче төрле әйткәндә, уку чаралары ярдәмендә тел һәм сөйләм материалын үзләштерүне күзаллый.

Дәрес типлары:

1) яңа материалны аңлату һәм ныгыту;
2) укучыларның сөйләм осталыкларын үстерү;
3) сөйләм күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү;
4) алган белемнәрне гомумиләштерү һәм системага салу;
5) белемнәрне тикшерү һәм контроль дәресләр.

Дәрес формалары:

1) дәрес-лекция, дәрес-аралашу, дәрес-әңгәмә, дәрес-хезмәт, дәрес-экскурсия, дәрес-кояш, дәрес-очрашу, дәрес-концерт, катнаш дәрес, дәрес-остаханә, дәрес-викторина, дәрес-уен;
2) мөстәкыйль эш дәресе, практик дәрес;
3) тикшерү (индивидуаль, группа белән, фронталь тикшерү, телдән (язма) рәвештә тикшерү, зачет, контроль яки мөстәкыйль эш).

Рус мәктәбендә татар теле дәресләрен җанлы һәм нәтиҗәле итеп уздыру өчен, Интернет челтәренең мөмкинлекләре бик зур. Интернет, үзенең барлык мөмкинлекләре һәм ресурслары белән бергә, телгә өйрәтү максат һәм бурычларын гамәлгә ашыру чарасы. Шуңа күрә дәрес алдыннан нинди дидактик максатка ирешү мәсьәләсен хәл итәргә, нинди ресурслар ярдәмгә килүен ачыкларга кирәк.

Төп максат – укучыларда аралашу компетенциясен булдыру, калганнары (белем бирү, тәрбия бирү, үстерү) төп максат гамәлгә ашырылганда хәл ителә. Бу уңайдан, татарча сайтлар, мультимедиа ресурслары ярдәмгә киләчәк. Шулай ук Интернеттан рус телендә булган материалларны файдалану да уңышлы булачак, чөнки телгә өйрәтү объекты – рус телле укучылар.

Шуны да истән чыгармыйк: сөйләм эшчәнлегенең телдән формаларын ике яки берничә кеше аралашканда гына өйрәтеп була. Компьютер программалары, CD-ROM диск, Интернет күпме дәрәҗәдә актив булмасын, ул бары тик квази аралашу гына (машина белән яки машина ярдәме белән) була. Искәрмә буларак, укучы компьютер аша (скайп, электрон почта) икенче яктан реаль шәхес белән (телдән һәм язма формада) әңгәмә кора ала.

Татар теленә өйрәткәндә, Интернет мөмкинлекләрен алдан ачыклау кирәк. Алар түбәндәгеләр булырга мөмкин: челтәр материалын дәрес структурасына кертеп җибәрү (белем бирү программасына җайлаштыру); проект өстендә эшләгәндә, укучының мөстәкыйль рәвештә белешмә эзләве; телне мөстәкыйль өйрәнгәндә, алган белем һәм күнекмәләрне камилләштергәндә, төрле конкурсларга, олимпиадаларга әзерләнгәндә һ.б.

Дәрес вакытында Интернетка турыдан-туры керү һәм аннан тиешле мәгълүмат алу күп очракта мөмкин дә түгел. Димәк, укытучы дәрес материалын алдан хәстәрләп куярга тиеш була.

Интернет челтәреннән уңышлы файдалану һәм аны дәрес структурасына дөрес, урынлы итеп җайлаштыру берничә дидактик максатны уңышлы хәл итәргә мөмкинлек тудыра:

- Интернеттагы аутентик тавышлы текстлар нигезендә тыңлап аңлауны камлләштерә;
- Интернет челтәре материалларын файдаланып, уку күнекмәләрен һәм осталыкларын формалаштыра;
- Интернет аркылы укытучы яки укучы алдан әзерләнгән материал нигезендә монологик һәм диалогик сөйләмне камилләштерә;
- Интернет материаллары, аеруча, проектлар төзегәндә тиешле ярдәм күрсәтә [6: 110-111].

Димәк, татар теле дәресләрендә заманча технологияләрне файдалану укытуның нәтиҗәлелеген арттыра һәм сыйфатын күтәрә, укучылар тарафыннан программада каралган тел һәм сөйләм материалын үзләштерү

җиңеләя, укучыларның тел һәм социокультура компетенцияләре киңәя, укыту процессын оештыру өчен уңайлы шартлар тудырыла һәм татар телен өйрәнүгә кызыксыну көчәя.

**Әдәбият**


1. *Харисов Ф.Ф.* Основы методики обучения татарскому языку как неродному / Под ред. проф. Л.З.Шакировой. СПб.: Филиал изд-ва «Просвещение», 2001. 431 с.
2. *Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М.* Татар телен чит тел буларак өйрәтү: заманча технологияләр. Казан: КДПУ, 2002. 36 б.
3. Иллюстрированный энциклопедический словарь. М.: Научное издательство «Большая Российская энциклопедия», 1995. С. 689, 390.
4. *Селевко Г.К.* Современные образовательные технологии: Учеб. пособие. М.: Народное образование, 1998. 256 с.
5. *Kharisov F.F., Kharisova Ch.* Bilingualism and multilingualism in a globalized society // Life Science Journal 2014; 11(11 s). P. 439-443.
6. *Нурова Л.А., Харисов Ф.Ф.* Особенности использования информационных и коммуникационных технологий на уроках татарского языка в начальной школе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тула, 2014. № 8-2 (38). С. 110-112.


---

# СОВРЕМЕННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ ОБУЧЕНИЯ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА


**Фираз Фахразович Харисов**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г.Казань, ул.Кремлевская, д.18,
harisov.52@mail.ru.



В настоящее время заметно активизировалось использование современных технологий в обучении. Речь идет не только об использовании новых технических средств, но и о формировании нового мышления в учебно-воспитательном процессе, о повышении качества образования с привлечением новых средств и методов обучения. Целью педагогов является активизация познавательной деятельности учащихся на уроках татарского языка, а также создание мотивации к изучению языка, формирование и развитие лингвистической, коммуникативной и культурологической компетенций школьников на основе действующей программы, тем самым учитель обязан выбирать соответствующие информационные и коммуникативные технологии с учетом цели и задач обучения данному предмету.

В статье дается обобщение и систематизация современных образовательных технологий, обоснование эффективности использования их в учебно-воспитательном процессе. Умелая организация образовательного пространства с использованием инновационных технологий способствует повышению объективности данных о качестве образования, позволяет вносить в его управление необходимые коррективы и создает условия для мотивации обучения языку.

В статье комментируются как традиционные, так и инновационные понятия, раскрывается специфика их использования в образовательной системе, подчеркивается эффективность используемых современных технологий при обучении татарскому языку.



**Ключевые слова:** традиция, современная технология, обучение, инновация, технология, Интернет-ресурс.